РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2025 ел №20

Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Кукмара шәһәре Советының 2018 елның 05 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (2022 елның 19 декабрендәге 31 номерлы, 2024 елның 21 июнендәге 13 номерлы, 2024 елның 20 августындагы 22 номерлы, 2024 елның 04 декабрендәге 37 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2 пунктындагы беренче абзацта «3990» саннарын «15389» саннарына алмаштырырга;

1.2. 2 өлешнең 7 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3 бүлек 1 пунктының 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Кукмара шәһәре мэры** **С.Д. Димитриев**